Татарстан Республикасы Законы

**Татарстан Республикасы**
**дәүләт бүләкләре турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2011 елның 15 сентябрендә
кабул ителде

Әлеге Закон Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләрен гамәлгә куя, Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләренең төрләрен һәм хокукый статусын урнаштыра һәм бүләкләү тәртибен билгели.

1 бүлек. **Гомуми нигезләмәләр**

1 статья. **Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре статусы**

Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре – Татарстан Республикасының дәүләти, икътисадый, социаль, фәнни һәм мәдәни үсешенә зур өлеш керткән өчен, законлылыкны ныгытудагы, гражданнарның сәламәтлеген һәм гомерен саклаудагы, хокукларын һәм ирекләрен яклаудагы, тәрбияләүдәге, спортны үстерүдәге казанышлары, актив хәйрия эшчәнлеге, Татарстан Республикасы һәм аның күпмилләтле халкы алдындагы башка казанышлар өчен бүләкләнүчеләрнең югары уңышларын дәүләти һәм иҗтимагый тануның иң югары чагылышы.

2 статья. **Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләренең төрләре**

1. Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре – Татарстан Республикасы ордены, медальләре һәм мактаулы исемнәре.

2. Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләнүгә тәкъдим ителгәндә бүләк төре бүләкләнүченең Татарстан Республикасы ордены статуты

һәм Татарстан Республикасы медальләре һәм мактаулы исемнәре турындагы нигезләмә нигезендә шәхси казанышларының характеры һәм дәрәҗәсе белән билгеләнә.

3 статья. **Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләренең тасвирламасы**

Татарстан Республикасы орденының, медальләренең һәм мактаулы исемнәренә күкрәк тамгаларының тасвирламасы Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан раслана.

4 статья. **Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләнүче субъектлар**

Татарстан Республикасы орденына, медальләренә һәм Татарстан Республикасының мактаулы исемнәренә Россия Федерациясе гражданнары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар (алга таба – гражданнар) лаек булырга мөмкин.

5 статья. **Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт бүләкләре комиссиясе**

Татарстан Республикасы Президенты, дәүләт бүләкләре белән бүләкләү буенча үзенең конституциячел вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итү өчен, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт бүләкләре комиссиясен төзи, аның составын һәм Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт бүләкләре комиссиясе турындагы нигезләмәне раслый.

6 статья. **Вафат булганнан соң бүләкләү**

Батырлык кылган, күрсәткән кыюлык һәм каһарманлык өчен Татарстан Республикасының дәүләт бүләкләре белән бүләкләү вафат булганнан соң да гамәлгә ашырылырга мөмкин.

2 бүлек. **Татарстан Республикасы ордены һәм медальләре**

7 статья. **Татарстан Республикасы ордены һәм медальләре**

Татарстан Республикасының түбәндәге ордены һәм медальләре гамәлгә кує-ла:

"Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен" ордены;

"Фидакарь хезмәт өчен" медале;

"Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлар өчен" медале;

"Ана даны – Материнская слава" медале;

"Өч миллиард тонна Татарстан нефтен чыгару уңаеннан" медале.

8 статья. **"Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен" орденының статуты**

1. "Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен" ордены Татарстан Республикасының иң югары дәүләт бүләге булып тора.

2. "Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен" ордены белән гражданнар Татарстан Республикасының дәүләтчелеген үстерүдәге, гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен тәэмин итүдәге, икътисадны, мәдәниятне, фәнне, мәгарифне, сәламәтлек саклауны, сәнгатьне һәм спортны үстерүдәге аерым казанышлары өчен, җәмәгать тәртибен саклаганда батырлык һәм кыюлык күрсәткән өчен бүләкләнәләр.

3. "Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен" орденына лаек булган затлар аны күкрәкнең сул ягына тагып йөриләр, ә бүләкләнүчеләрнең Россия Федерациясе, СССР орденнары һәм медальләре булганда, алардан соң урнаштыралар.

4. "Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен" орденын көн саен тагып йөрү өчен орден планкасы кулланыла. Орденны орден планкасы белән тагып йөрү рөхсәт ителми.

5. Орден планкасын күкрәкнең сул ягына тагып йөриләр, ә бүләкләнүчеләрнең Россия Федерациясе, СССР орденнары планкалары һәм медальләре булганда, алардан соң урнаштыралар.

9 статья. **"Фидакарь хезмәт өчен" медале турындагы нигезләмә**

1. "Фидакарь хезмәт өчен" медале белән гражданнар Татарстан Республикасының дәүләти, икътисадый, социаль һәм мәдәни үсеше өлкәсендәге, республиканың икътисадый һәм фәнни куәтен арттырудагы хезмәттә югары уңышлары өчен, актив җәмәгать һәм хәйрия эшчәнлеге өчен бүләкләнәләр.

2. "Фидакарь хезмәт өчен" медаленә лаек булган затлар аны күкрәкнең сул ягына тагып йөриләр, ә бүләкләнүчеләрнең Россия Федерациясе, СССР орденнары һәм медальләре, "Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен" ордены булганда, алардан соң урнаштыралар.

10 статья. **"Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлар өчен" медале турында нигезләмә**

1. "Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлар өчен" медале белән гражданнар Татарстан Республикасында җирле үзидарәне торгызудагы һәм үстерүдәге, җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттырудагы, тарихи һәм башка җирле традицияләрне исәпкә алып, халык мәнфәгатьләреннән чыгып, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүдәге аерым казанышлары өчен бүләкләнәләр.

2. "Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлар өчен" медаленә лаек булган затлар аны күкрәкнең сул ягына тагып йөриләр, ә

бүләкләнүчеләрнең Россия Федерациясе, СССР орденнары һәм медальләре, "Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен" ордены, "Фидакарь хезмәт өчен" медале булганда, алардан соң урнаштыралар.

11 статья. **"Ана даны – Материнская слава" медале турында нигезләмә**

1. "Ана даны – Материнская слава" медале – ана булуның югары дәрәҗәдәге билгесе, һәм ул ана булган хатын-кызның иҗтимагый танылуын һәм аңа олы ихтирамны тәэмин итү максатларында гамәлгә куела.

2. "Ана даны – Материнская слава" медале белән аналар – Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче, биш һәм күбрәк бала тудырган һәм тәрбияләп үстерүче (тәрбияләгән), кимендә бер балигъ булмаган балалы Россия Федерациясе гражданнары бүләкләнә. Бүләкләнүгә тәкъдим ителгәндә, күп балалы ананың үз балаларын тәрбияләүгә намуслы мөнәсәбәте исәпкә алына.

3. "Ана даны – Материнская слава" медале белән бүләкләү Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә, бишенче бала өч яшькә җиткәч һәм, әлеге статьяда каралган очраклардан тыш, калган башка балалар исән булганда башкарыла.

4. "Ана даны – Материнская слава" медале белән бүләкләнүгә тәкъдим ителгәндә, шулай ук түбәндәге балалар игътибарга алына:

1) ана законда билгеләнгән тәртиптә уллыкка яисә кызлыкка алган;

2) Ватанны саклаганда яисә башка хәрби бурычларны үтәгәндә йә кеше гомерен коткару буенча, законлылыкны һәм хокук тәртибен саклау буенча граждан бурычын үтәгәндә һәлак булган яисә хәбәрсез югалган, шулай ук күрсәтелгән шартларда яралану, контузия алу, гарипләнү яисә авыру сәбәпле, йә хезмәттә гарипләнү яисә һөнәри авыру аркасында, йә бәхетсезлек очраклары, һәлакәтләр, табигый бәла-казалар аркасында вафат булганнар.

5. Уллыкка (кызлыкка) бала алучыларны "Ана даны – Материнская слава" медале белән бүләкләү кимендә өч ел дәвамында уллыкка (кызлыкка) алынган балаларны лаеклы тәрбияләү һәм карап тоту шартларында башкарыла.

6. "Ана даны – Материнская слава" медаленә лаек булган затлар аны күкрәкнең сул ягына тагып йөриләр, ә бүләкләнүчеләрнең башка орденнары һәм медальләре булганда, "Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлар өчен" медаленнән соң урнаштыралар.

12 статья. **"Өч миллиард тонна Татарстан нефтен чыгару уңаеннан" медале турында нигезләмә**

1. "Өч миллиард тонна Татарстан нефтен чыгару уңаеннан" медале белән Татарстан Республикасы сәнәгатенең нефть тармагындагы хезмәттә югары күрсәткечләргә ирешкән хезмәткәрләре, шул исәптән оештыру-хокукый рәвешләренә бәйсез рәвештә Татарстан Республикасы сәнәгатенең нефть тармагы предприятиеләренең һәм оешмаларының үзләре җитәкләгән коллективлар белән бергә эшләрендә югары нәтиҗәләргә ирешкән җитәкчеләре, шулай ук Татарстан Республикасы халык хуҗалыгының башка тармаклары, дәүләт органнары һәм

оешмалары хезмәткәрләре булып торучы (булган), Татарстан Республикасы нефть сәнәгатен торгызуга һәм үстерүгә зур өлеш керткән гражданнар бүләкләнә.

2. "Өч миллиард тонна Татарстан нефтен чыгару уңаеннан" медаленә лаек булган затлар аны күкрәкнең сул ягына тагып йөриләр, ә бүләкләнүчеләрнең башка орденнары һәм медальләре булганда, "Ана даны – Материнская слава" медаленнән соң урнаштыралар.

3 бүлек. **Татарстан Республикасы мактаулы исемнәре**

13 статья. **Татарстан Республикасы мактаулы исемнәренең төрләре**

Татарстан Республикасында түбәндәге мактаулы исемнәр билгеләнә:

1) "Татарстан Республикасының Халык артисты";

2) "Татарстан Республикасының Халык язучысы";

3) "Татарстан Республикасының Халык шагыйре";

4) "Татарстан Республикасының Халык укытучысы";

5) "Татарстан Республикасының Халык рәссамы";

6) "Татарстан Республикасының Атказанган агрономы";

7) "Татарстан Республикасының Атказанган артисты";

8) "Татарстан Республикасының Атказанган архитекторы";

9) "Татарстан Республикасының Атказанган ветеринария табибы";

10) "Татарстан Республикасының Атказанган табибы";

11) "Татарстан Республикасының Атказанган геологы";

12) "Татарстан Республикасының Атказанган сәнгать эшлеклесе";

13) "Татарстан Республикасының Атказанган фән эшлеклесе";

14) "Татарстан Республикасының Атказанган терлекчесе";

15) "Татарстан Республикасының Атказанган җиртөзәре";

16) "Татарстан Республикасының Атказанган зоотехнигы";

17) "Татарстан Республикасының Атказанган уйлап табучысы";

18) "Татарстан Республикасының Атказанган урманчысы";

19) "Татарстан Республикасының Атказанган машина төзүчесе";

20) "Татарстан Республикасының Атказанган мелиораторы";

21) "Татарстан Республикасының Атказанган авыл хуҗалыгы механизаторы";

22) "Татарстан Республикасының Атказанган нефтьчесе";

23) "Татарстан Республикасының Атказанган югары мәктәп хезмәткәре";

24) "Татарстан Республикасының Атказанган торак-коммуналь хуҗалыгы хезмәткәре";

25) "Татарстан Республикасының Атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре";

26) "Татарстан Республикасының Атказанган мәдәният хезмәткәре";

27) "Татарстан Республикасының Атказанган җиңел сәнәгать хезмәткәре";

28) "Татарстан Республикасының Атказанган азык-төлек сәнәгате хезмәткәре";

29) "Татарстан Республикасының Атказанган мәгълүматлаштыру һәм элемтә хезмәткәре";

30) "Татарстан Республикасының Атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре";

31) "Татарстан Республикасының Атказанган халыкны социаль яклау хезмәткәре";

32) "Татарстан Республикасының Атказанган халыкка хезмәт күрсәтү өлкәсе хезмәткәре";

33) "Татарстан Республикасының Атказанган транспорт хезмәткәре";

34) "Татарстан Республикасының Атказанган физик культура хезмәткәре";

35) "Татарстан Республикасының Атказанган рационализаторы";

36) "Татарстан Республикасының Атказанган эчке эшләр органнары хезмәткәре";

37) "Татарстан Республикасының Атказанган коткаручысы";

38) "Татарстан Республикасының Атказанган төзүчесе";

39) "Татарстан Республикасының Атказанган укытучысы";

40) "Татарстан Республикасының Атказанган химигы";

41) "Татарстан Республикасының Атказанган экологы";

42) "Татарстан Республикасының Атказанган икътисадчысы";

43) "Татарстан Республикасының Атказанган энергетигы";

44) "Татарстан Республикасының Атказанган юристы".

14 статья. **Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре турындагы нигезләмә**

Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре түбәндәгеләргә бирелә:

1) "Татарстан Республикасының Халык артисты" – югары осталыкка ия булган, күренекле сәнгать образлары, спектакльләр, кинофильмнар, телеспектакльләр, телефильмнар, концерт, эстрада, цирк программалары, музыкаль, телевизион һәм радио әсәрләре иҗат иткән һәм республиканың сәнгати мәдәниятенә зур өлеш керткән, җәмәгатьчелеккә киң танылган артистларга, режиссерларга, балетмейстерларга, дирижерларга, хормейстерларга, музыкаль башкаручыларга һәм башка сәнгать әһелләренә. "Татарстан Республикасының Атказанган артисты" яисә "Татарстан Республикасының Атказанган сәнгать эшлеклесе" дигән мактаулы исемнәр бирелгәннән соң, кагыйдә буларак, кимендә 10 ел узгач бирелә (беренче партияләрне башкаручы балет артистларына кимендә биш ел узгач бирелә);

2) "Татарстан Республикасының Халык язучысы" һәм "Татарстан Республикасының Халык шагыйре" – иң күренекле, киң танылган сәнгать әсәрләре иҗат иткән шагыйрьләргә, язучыларга, драматургларга, прозаикларга;

3) "Татарстан Республикасының Халык укытучысы" – мәгарифкә зур өлеш керткән һәм җәмәгатьчелектә киң танылган укытучыларга, мөгаллимнәргә, тәрбиячеләргә һәм мәгариф учреждениеләренең башка хезмәткәрләренә. "Татарстан Рес-

публикасының Атказанган укытучысы" мактаулы исеме бирелгәннән соң, кагыйдә буларак, кимендә биш ел узгач бирелә;

4) "Татарстан Республикасының Халык рәссамы" – рәсем сәнгате, сынлы сәнгать, графика, монументаль, декоратив-гамәли, театр, кино һәм телевидение сәнгатендә иң күренекле әсәрләр иҗат иткән, республиканың сәнгати мәдәниятенә аерым өлеш керткән һәм җәмәгатьчелектә киң танылган күренекле рәссамнарга;

5) "Татарстан Республикасының Атказанган агрономы" – үз белгечлеге буенча кимендә 10 ел эшләүче югары профессиональ агрономнарга игенчелекне фәнни нигезләргә таянып алып бару нигезендә алынган экологик яктан чиста авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерүнең югары икътисадый нәтиҗәлелегенә ирешкән, туфрак уңдырышлылыгын яңадан яхшырту буенча нәтиҗәле агроалымнар комплексын тәэмин иткән, үсемлекләр селекциясе һәм аларны яклау буенча уңышлы эшләгән, орлыкчылыклы һәм орлык алыштыруны үрнәк булырлык итеп куйган, табигый терлек азыгы җирләрен нәтиҗәле алып барган һәм файдаланган өчен;

6) "Татарстан Республикасының Атказанган артисты" – җәмәгатьчелеккә танылган югары сәнгать образлары, спектакльләр, кинофильмнар, телеспектакльләр, телефильмнар, концерт, эстрада, цирк программалары, музыкаль, телевизион һәм радио әсәрләре иҗат иткән, сәнгать өлкәсендә кимендә 10 ел эшләүче югары профессиональ артистларга, режиссерларга, балетмейстерларга, дирижерларга, хормейстерларга, музыкаль башкаручыларга һәм башка сәнгать әһелләренә;

7) "Татарстан Республикасының Атказанган архитекторы" – белгечлекләре буенча кимендә 10 ел эшләүче югары квалификацияле архитекторларга, реставраторларга, шәһәр төзүчеләргә, югары уку йортлары мөгаллимнәренә шәһәр төзелеше өлкәсендәге, граждан, сәнәгать һәм авыл архитектура комплекслары, биналар һәм корылмалар төзүдәге һәм реконструкцияләүдәге, җәмәгатьчелеккә киң танылган тарих һәм мәдәният ядкарьләрен торгызудагы, архитектура өлкәсендә фәннитикшеренү эшендәге, кадрлар әзерләүдәге казанышлары өчен;

8) "Татарстан Республикасының Атказанган ветеринария табибы" – авыл хуҗалыгы җитештерүендә, терлек авыруларына каршы көрәш станцияләрендә, фәнни-тикшеренү һәм башка ветеринария учреждениеләрендә, дәүләт ветеринария инспекциясендә, транспорттагы, дәүләт чикләрендәге дәүләт ветеринария күзәтчелеге органнарында һәм башка дәүләт ветеринария учреждениеләрендә белгечлеге буенча кимендә 10 ел эшләүче югары профессиональ ветеринария табибларына ветеринария, терлекчелекне үстерү, аның продуктлылыгын арттыру өлкәсендәге казанышлары өчен;

9) "Татарстан Республикасының Атказанган табибы" – табиблык участокларының, амбулаторияләрнең, поликлиникаларның, бала тудыру йортларының, хастаханәләрнең, башка дәвалау-профилактика, санитария-профилактика, шифаханә-курорт учреждениеләренең, халыкның сәламәтлеген саклау, социаль яклау буенча башка учреждениеләрнең, фәнни-тикшеренү институтларының, уку йортларының, сәламәтлек саклау һәм санитария-эпидемиология күзәтчелеге органнарының белгечлеге буенча кимендә 10 ел эшләүче югары профессиональ табибларына халыкның сәламәтлеген саклаудагы, дәвалау-профилактика ярдәмен

медицина фәне һәм техникасының заманча казанышларын практикада кулланып оештырудагы, медицина кадрлары әзерләүдәге казанышлары өчен;

10) "Татарстан Республикасының Атказанган геологы" – геология оешмаларында, фәнни-тикшеренү геология учреждениеләрендә кимендә 10 ел эшләүче, геология, геофизика хезмәтләренең, уку йортларының югары квалификацияле хезмәткәрләренә геологик эзләнү производствосын үстерүдәге, минераль-чимал базасын ныгытудагы, геологик эзләнү эшләренең юнәлешләрен фәнни нигезләүдәге казанышлары өчен, файдалы казылмалар ятмаларын эзләгән, ачкан, разведка ясаган һәм сәнәгать үзләштерүенә тапшырган, экологик чиста технологияләрне эшләгән һәм гамәлгә керткән, кадрлар әзерләгән өчен;

11) "Татарстан Республикасының Атказанган сәнгать эшлеклесе" – мәдәниятне һәм сәнгатьне үстерүгә мөһим өлеш керткән һәм сәнгать өлкәсендә кимендә 10 ел эшләүче югары профессиональ режиссерларга, балетмейстерларга, дирижерларга, хормейстерларга, композиторларга, драматургларга, рәссамнарга, архитекторларга, дизайнерларга, сәнгать белгечләренә һәм башка сәнгать әһелләренә, шагыйрьләргә һәм язучыларга иҗади кадрлар тәрбияләүдәге һәм әзерләүдәге, сәнгать өлкәсендә фәнни хезмәтләр иҗат итүдәге зур казанышлары өчен;

12) "Татарстан Республикасының Атказанган фән эшлеклесе" – белгечлекләре буенча кимендә 10 ел эшләүче, фәннәр докторы гыйльми дәрәҗәсенә ия булган югары квалификацияле фәнни хезмәткәрләргә фән һәм техника, ачышлар һәм уйлап табулар өлкәсендә булган аеруча кыйммәтле хезмәтләре өчен яисә республикада аеруча күренекле фәнни-гамәли эшчәнлек алып барган өчен, фән һәм техниканың өстенлекле юнәлешләрен эшләүдәге, фәнни мәктәпләр булдырудагы, фәнни кадрлар тәрбияләүдәге һәм әзерләүдәге казанышлары өчен;

13) "Татарстан Республикасының Атказанган терлекчесе" – югары җитештерү күрсәткечләренә ирешкән һәм белгечлекләре буенча кимендә 10 ел эшләүче югары профессиональ терлекчеләргә терлекчелекне үстерүне тәэмин итүдәге, терлекләрнең продуктивлылыгын күтәрүдәге, терлекчелек продукциясенең сыйфатын яхшыртудагы казанышлары өчен;

14) "Татарстан Республикасының Атказанган җиртөзәре" – белгечлекләре буенча кимендә 10 ел эшләүче югары профессиональ җир төзүче инженерларга һәм техникларга җир төзү өлкәсендә республикада җирдән нәтиҗәле файдалануны планлаштырудагы һәм оештырудагы казанышлары өчен;

15) "Татарстан Республикасының Атказанган зоотехнигы" – авыл хуҗалыгы җитештерүендә, авыл хуҗалыгы предприятиеләрендә һәм учреждениеләрендә белгечлекләре буенча кимендә 10 ел эшләүче югары профессиональ зоотехникларга терлекчелекне үстерүне, аның продуктивлыгын күтәрүне зоотехник яктан тәэмин итүдәге казанышлары өчен;

16) "Татарстан Республикасының Атказанган уйлап табучысы" – республика әһәмиятенә ия булган һәм җитештерүгә кертелгән уйлап табуларның республика техник алгарышына мөһим өлеш керткән авторларына;

17) "Татарстан Республикасының Атказанган урманчысы" – үз белгечлекләре буенча кимендә 10 ел эшләүче, урман хуҗалыкларының, урман сәнәгате хуҗалыкларының, урман комбинатларының, урман һәм җиләк-җимеш питом-

никларының, фәнни-тикшерену, урман төзелеше, проект-эзләнү һәм урман хуҗалыгының башка учреждениеләренең, предприятиеләренең һәм оешмаларының югары квалификацияле белгечләренә, табигатьне саклау органнарының һәм оешмаларының хезмәткәрләренә республика урман хуҗалыгын үстерүдәге, урман байлыкларын саклаудагы һәм ишәйтүдәге, үсемлекләр, хайваннар дөньясын саклап калудагы, экологик проблемаларны хәл итүдәге казанышлары өчен;

18) "Татарстан Республикасының Атказанган машина төзүчесе" – машина төзелеше предприятиеләренең, берләшмәләренең, учреждениеләренең һәм оешмаларының машина төзелеше өлкәсендә кимендә 10 ел эшләүче югары профессиональ эшчеләренә, инженер-техник һәм фәнни хезмәткәрләренә җитештерү бурычларын үтәүдәге, яңа техника, технология эшләүдәге һәм гамәлгә кертүдәге, продукция сыйфатын яхшыртудагы, хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрүдәге, җитештерүнең югары нәтиҗәле эшчәнлеген тәэмин итүдәге казанышлары өчен;

19) "Татарстан Республикасының Атказанган мелиораторы" – мелиорация өлкәсендә кимендә 10 ел эшләүче югары профессиональ эшчеләргә, инженер-техник һәм фәнни хезмәткәрләргә җитештерү бурычларын үтәүдәге, мелиорация эшләренең сыйфатын яхшыртудагы, мелиорация системаларын эксплуатацияләүдәге, табигать ресурсларын саклаудагы, мелиораторлар кадрларын әзерләүдәге казанышлары өчен;

20) "Татарстан Республикасының Атказанган авыл хуҗалыгы механизаторы" – авыл хуҗалыгы предприятиеләренең, учреждениеләренең һәм оешмаларының авыл хуҗалыгы өлкәсендәге белгечлекләр буенча кимендә 10 ел эшләүче югары профессиональ механизаторларына, техник-механикларына авыл хуҗалыгын механикалаштыру өлкәсендәге казанышлары, авыл хуҗалыгы техникасыннан файдалануда югары күрсәткечләргә ирешүләре өчен;

21) "Татарстан Республикасының Атказанган нефтьчесе" – нефть сәнәгате предприятиеләренең, берләшмәләренең, фәнни-тикшеренү, технологик, проект-конструкторлык һәм башка оешмаларының шушы тармакта кимендә 10 ел эшләүче югары профессиональ эшчеләренә, осталарына, инженер-техник, фәнни хезмәткәрләренә республиканың нефть сәнәгатен үстерүдәге, фәнни-техник һәм экологик программаларны эшләүдәге һәм гамәлгә ашырудагы, нефть ятмаларын үзләштерүдәге казанышлары өчен;

22) "Татарстан Республикасының Атказанган югары мәктәп хезмәткәре" – белгечлекләре буенча кимендә 10 ел эшләүче һәм кимендә җиде ел педагогик стажы булган югары профессиональ мөгаллимнәргә, югары, югары уку йортыннан соңгы һөнәри белем, тиешле өстәмә белем системасы һәм югары белемгә идарә итү буенча дәүләт органнары хезмәткәрләренә укыту һәм фәнни эшләрендәге казанышлары, югары квалификацияле белгечләр әзерләү эшенә мөһим өлеш керткән өчен;

23) "Татарстан Республикасының Атказанган торак-коммуналь хуҗалыгы хезмәткәре" – торак-коммуналь хуҗалык предприятиеләренең, оешмаларының һәм учреждениеләренең торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә кимендә 10 ел эшләүче, җитештерүнең нәтиҗәлелеген күтәрүдә, яңа техниканы, хезмәт күрсәтүләрнең яңа төрләрен, хезмәтнең алдынгы алымнарын гамәлгә кертүдә, тармакның матди-

техник базасын камилләштерүдә һәм алга таба үстерүдә, торак фондының һәм коммуналь хуҗалык объектларының сакланышын тәэмин итүдә һәм аларны эксплуатацияләүне яхшыртуда, җитештерүнең икътисадый нәтиҗәлелеген, күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфатын күтәрүдә, халыкка хезмәт күрсәтү буенча югары культуралылыкны тәэмин итүдә аерым осталык күрсәткән югары квалификацияле хезмәткәрләренә коммуналь хуҗалыкның тотрыклы һәм сыйфатлы эшчәнлеген оештырудагы казанышлары өчен;

24) "Татарстан Республикасының Атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре" – сәламәтлек саклау өлкәсендә кимендә 10 ел эшләүче югары квалификацияле урта һәм кече медицина хезмәткәрләренә, провизорларга, фармацевтларга, инженер-техник хезмәткәрләргә, дәвалау-профилактикалау, шифаханә-курорт, даруханә учреждениеләренең, сәламәтлек саклау, халыкны социаль яклау органнарының, фәнни-тикшеренү, медицина һәм фармацевтика институтларының, кайсы ведомствога буйсынуларына бәйсез рәвештә предприятиеләрнең, учреждениеләрнең, оешмаларның хезмәт күрсәтүче һәм башка персоналына халыкның сәламәтлеген саклаудагы, медицина ярдәменең һәм дарулар белән тәэмин итүнең сыйфатын күтәрүдәге казанышлары өчен;

25) "Татарстан Республикасының Атказанган мәдәният хезмәткәре" – мәдәният өлкәсендә кимендә 10 ел эшләүче һәм аны үстерүдә зур казанышларга ия булган, мәдәният учреждениеләренең, оешмаларының һәм органнарының, мәдәни-агарту учреждениеләренең, кинематографиянең, телевидение һәм радиотапшыруларның, матбугатның, нәшриятның, полиграфия сәнәгатенең һәм китап сәүдәсенең, туристлык-экскурсия оешмаларының һәм учреждениеләренең югары квалификацияле хезмәткәрләренә, мәдәният һәм сәнгать уку йортлары хезмәткәрләренә, үзешчән иҗатта катнашучыларга һәм мәдәният оешмалары, учреждениеләре һәм органнары эшендә җәмәгатьчелек башлангычларында катнашучы затларга;

26) "Татарстан Республикасының Атказанган җиңел сәнәгать хезмәткәре" – җиңел сәнәгатьнең әлеге тармакта кимендә 10 ел эшләүче югары квалификацияле хезмәткәрләренә җитештерүнең нәтиҗәлелеген күтәрүдәге, фән һәм техника казанышларын гамәлгә кертү, технологияне камилләштерү, җитештерү процессларын механикалаштыру һәм автоматлаштыру исәбенә продукция эшләп чыгаруны арттырудагы, аның сыйфатын яхшыртудагы, яңа төр эшләнмәләр ассортиментын киңәйтүдәге казанышлары өчен;

27) "Татарстан Республикасының Атказанган азык-төлек сәнәгате хезмәткәре" – сәнәгатьнең азык-төлек, ит, сөт һәм шәраб әзерләү тармаклары, кулланучылар кооперациясе предприятиеләренең, берләшмәләренең, учреждениеләренең һәм оешмаларының шушы сәнәгать һәм куллану кооперациясе тармакларында кимендә 10 ел эшләүче югары квалификацияле эшчеләренә, инженер-техник һәм фәнни хезмәткәрләренә азык-төлек продукциясенең сыйфатын яхшыртудагы һәм ассортиментын киңәйтүдәге, техниканы һәм технологияне камилләштерүдәге, куәтләрдән һәм матди ресурслардан нәтиҗәле файдаланудагы, квалификацияле кадрлар әзерләүдәге казанышлары өчен;

28) "Татарстан Республикасының Атказанган мәгълүматлаштыру һәм элемтә хезмәткәре" – мәгълүматлаштыру һәм элемтә тармагы предприятиеләренең һәм оешмаларының мәгълүматлаштыру һәм элемтә өлкәсендә кимендә 10 ел эшләүче югары квалификацияле хезмәткәрләренә элемтә чараларын үстерүдәге һәм камилләштерүдәге, шулай ук аларның югары сыйфатлы, тоткарлыксыз эшләвен тәэмин итүдәге, инфокоммуникация инфраструктурасы эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттырудагы, халыкка, республика предприятиеләренә, учреждениеләренә һәм оешмаларына элемтәнең барлык төрләре хезмәт күрсәтүне һәм инфокоммуникация хезмәтләре күрсәтүне яхшыртудагы, принципиаль яңа югары нәтиҗәле техника һәм технология эшләүдәге һәм аларны гамәлгә кертүдәге казанышлары өчен;

29) "Татарстан Республикасының Атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре" – авыл хуҗалыгы өлкәсендә кимендә 10 ел эшләүче һәм авыл хуҗалыгының югары квалификацияле белгечләр әзерләүгә мөһим өлеш керткән югары профессиональ хезмәткәрләренә, шул исәптән крестьян (фермер) хуҗалыкларының, фәнни-тикшеренү учреждениеләренең, авыл хуҗалыгы юнәлешендәге уку йортларының, тәҗрибә станцияләренең, авыл хуҗалыгына идарә итү органнарының хезмәткәрләренә, авыл хуҗалыгы җитештерүен оештыручыларга авыл хуҗалыгы культураларының уңышын һәм җыемын арттырудагы, туфракның уңдырышлылыгын, терлекләрнең һәм кош-кортларның продуктивлыгын күтәрүдәге, үсемлекчелек һәм терлекчелек продукциясен җитештерүне, дәүләткә һәм халыкка сатуны арттырудагы, авыл хуҗалыгы продукциясенең сыйфатын яхшыртудагы һәм үзкыйммәтен киметүдәге, хезмәт җитештерүчәнлеген арттырудагы, фән һәм техника уңышларын җитештерүгә кертүдәге казанышлары өчен;

30) "Татарстан Республикасының Атказанган халыкны социаль яклау хезмәткәре" – республика халкын социаль яклау системасы органнарының, учреждениеләренең һәм предприятиеләренең халыкны социаль яклау өлкәсендә кимендә 10 ел эшләүче югары профессиональ хезмәткәрләренә халыкны социаль тәэмин итүне, аңа социаль булышуны (ярдәм итүне), аны социаль иминләштерүне һәм эш белән тәэмин итүне оештырудагы, мохтаҗларга хәйриянең төрле рәвешләрен һәм төрләрен үстерүдәге, халыкны социаль яклауның иң мөһим юнәлешләре буенча фәнни тикшеренүләр уздырудагы аерым казанышлары өчен;

31) "Татарстан Республикасының Атказанган халыкка хезмәт күрсәтү өлкәсе хезмәткәре" – халыкка хезмәт күрсәтү өлкәсендә кимендә 10 ел эшләүче, дәүләти, кооператив, хосусый сәүдәнең, җәмәгать туклануының һәм халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтүнең, әлеге юнәлештәге уку йортларының югары квалификацияле хезмәткәрләренә халыкка хезмәт күрсәтү өлкәсен үстерүдәге, эш оештыру рәвешләрен һәм ысулларын камилләштерүдәге, предприятиеләрнең һәм оешмаларның матди-техник базасын киңәйтүдәге һәм ныгытудагы, халыкка хезмәт күрсәтүнең югары культуралылыгын тәэмин итүдәге, кадрлар әзерләү дәрәҗәсен күтәрүдәге казанышлары өчен;

32) "Татарстан Республикасының Атказанган транспорт хезмәткәре" – автомобиль, су, һава, тимер юл һәм башка төр транспортның, уку йортларының

транспорт өчен квалификацияле кадрлар әзерләүгә өлеш керткән һәм транспорт тармагында кимендә 10 ел эшләүче югары квалификацияле хезмәткәрләренә транспортның техник чараларын җитештерүнең нәтиҗәлелеген күтәрүдәге һәм алардан файдалануны яхшыртудагы, пассажир-йөк ташуларның үзкыйммәтен киметүдәге, транспорт хезмәтләре сыйфатын яхшыртудагы, матди һәм ягулык ресурсларын экономияләүдәге, хәрәкәт иминлеген, әйләнә-тирә мохитне саклауны тәэмин итүдәге, пассажирларга хезмәт күрсәтүнең югары культуралылыгын тәэмин итүдәге казанышлары өчен;

33) "Татарстан Республикасының Атказанган физик культура хезмәткәре" – республиканың физик культура һәм спорт өлкәсендә кимендә 10 ел эшләүче физкультура хәрәкәтен оештыручыларга, галимнәргә һәм тренерларга, физик культура коллективларының, спорт корылмаларының, физкультура оешмаларының, уку йортларының, фәнни-тикшеренү институтларының хезмәткәрләренә оештыру-методик, укыту-күнекмә, фәнни-педагогик, тәрбия, инженер-техник һәм хуҗалык эшчәнлегендәге, халыкны физик тәрбияләү системасын, массакүләм спортны, иң югары казанышлар спортын камилләштерүдәге казанышлары өчен;

34) "Татарстан Республикасының Атказанган рационализаторы" – тәкъдимнәрен гамәлгә кертү җитештерүне камилләштерүгә, хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрүгә, продукция сыйфатын, хезмәт шартларын һәм куркынычсызлык техникасын яхшыртуга, фәнни-тикшеренү һәм укыту процессын тәэмин итүгә мөһим өлеш керткән, озак еллар буе уңышлы рационализаторлык эшчәнлеген алып баручы рационализаторлык тәкъдимнәре авторларына;

35) "Татарстан Республикасының Атказанган эчке эшләр органнары хезмәткәре" – Татарстан Республикасы эчке эшләр органнарының Татарстан Республикасы эчке эшләр органнарында кимендә 10 ел хезмәт итүче югары квалификацияле хезмәткәрләренә хокук тәртибен саклаудагы, җинаятьчелеккә каршы көрәштәге, җәмәгать иминлеген тәэмин итүдәге, фәнне үстерүдәге, эчке эшләр органнары кадрларын әзерләүдәге һәм тәрбияләүдәге аерым казанышлары өчен;

36) "Татарстан Республикасының Атказанган коткаручысы" – коткару хезмәтләренең шул тармакларда кимендә 10 ел эшләүче югары профессиональ хезмәткәрләренә һәлакәтләрне, афәтләрне һәм табигый бәла-казаларны булдырмый калудагы һәм алардан килгән зыянны бетерүдәге, яңа коткару техникасын эшләүдәге һәм үзләштерүдәге, кадрлар тәрбияләүдәге һәм укытудагы казанышлары өчен;

37) "Татарстан Республикасының Атказанган төзүчесе" – төзелеш тармагында кимендә 10 ел эшләүче, төзелеш һәм ремонт-төзелеш оешмаларының, төзелеш материаллары предприятиеләренең югары квалификацияле хезмәткәрләренә, фәнни-тикшеренү һәм проект институтларының, уку йортларының, конструкторлык бюроларының һәм лабораторияләренең, төзелеш тармагына идарә итү органнарының хезмәткәрләренә җитештерү эшчәнлегендәге, прогрессив проектларны һәм технологияләрне, эшләр оештыруның алдынгы тәҗрибәсен эшләүдәге һәм гамәлгә кертүдәге, хезмәтне механикалаштырудагы һәм

автоматлаштырудагы, төзелеш эшләре җитештерүенең һәм сыйфатының югары нәтиҗәлелегенә ирешүдәге, квалификацияле кадрлар әзерләүдәге казанышлары өчен;

38) "Татарстан Республикасының Атказанган укытучысы" – белгечлекләре буенча кимендә 10 ел эшләүче югары профессиональ укытучыларга, мөгаллимнәргә, тәрбиячеләргә һәм мәктәпкәчә учреждениеләрнең, барлык төрдәге гомуми белем бирү учреждениеләренең, өстәмә (мәктәптән тыш) белем бирү учреждениеләренең, балалар йортларының, башлангыч һәм урта һөнәри белем бирү учреждениеләренең, югары педагогик белем бирү учреждениеләренең, мәгариф хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү институтларының, мәгариф идарәсе органнарының, мәгариф системасы фәнни-тикшеренү институтларының башка хезмәткәрләренә укучылар һәм тәрбияләнүчеләр тарафыннан тирән белем алуны, аларның иҗат куәтен үстерүне һәм камилләштерүне тәэмин итә торган педагогик һәм тәрбияви эшчәнлектәге, инновацион укыту-методик ярдәмлекләр, программалар, автор методикалары булдырудагы, белем бирү процессын фәнни-методик тәэмин итүдә катнашудагы казанышлары өчен;

39) "Татарстан Республикасының Атказанган химигы" – химия, нефть эшкәртү һәм нефть химиясе сәнәгате предприятиеләрендә, берләшмәләрендә, фәнни-тикшеренү, технологик, проект-конструкторлык һәм башка оешмаларында, сәнәгатьнең башка тармакларының шундый профильдәге предприятиеләрендә, оешмаларында, тиешле профильдәге уку йортларында кимендә 10 ел эшләүче һәм химия, нефть химиясе, нефть эшкәртү сәнәгатенең фәнни-техник алгарышына, химия, нефть химиясе һәм нефть эшкәртү производстволарын булдыруга һәм үстерүгә, кадрлар әзерләүгә мөһим өлеш керткән югары профессиональ эшчеләргә, осталарга, инженер-техник һәм фәнни хезмәткәрләргә производство бурычларын үтәүдәге, продукциянең сыйфатын яхшыртудагы һәм үзкыйммәтен киметүдәге, техниканы һәм технологияне камилләштерүдәге, продукциянең яңа төрләрен булдырудагы һәм үзләштерүдәге, хезмәт җитештерүчәнлеген һәм җитештерү нәтиҗәлелеген күтәрүдәге казанышлары өчен;

40) "Татарстан Республикасының Атказанган экологы" – әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигатьтән нәтиҗәле файдалану өлкәсендә кимендә 10 ел эшләүче, табигатьне саклау органнарының югары профессиональ хезмәткәрләренә, предприятиеләрнең һәм оешмаларның эшчеләренә, инженер-техник хезмәткәрләренә һәм хезмәт күрсәтүчеләренә, фәнни-тикшеренү, проект, технологик һәм җитештерү оешмаларының, башка учреждениеләрнең экология проблемалары белән шөгыльләнүче хезмәткәрләренә табигать ресурсларын саклаудагы, аз калдыклы һәм калдыксыз технологияләр эшләүдәге һәм үзләштерүдәге, тузан һәм газ тотып кала торган җайланмалар һәм чистарту корылмалары төзүдәге, үсемлекләр һәм хайваннар дөньясын саклаудагы казанышлары өчен;

41) "Татарстан Республикасының Атказанган икътисадчысы" – белгечлекләре буенча кимендә 10 ел эшләүче югары квалификацияле икътисадчыларга, бухгалтерларга, икътисад һәм финанс эшчәнлеге өлкәсендәге башка белгечләргә предприятиенең, учреждениенең, оешманың югары икътисадый

күрсәткечләргә ирешүенә, республиканың һәм аның аерым территорияләренең икътисадый үсешенә ярдәм итә торган икътисад һәм финанс эшләрен, исәпкә алуны һәм контрольдә тотуны яхшыртудагы һәм камилләштерүдәге, икътисад фәнен үстерүдәге, кадрлар әзерләүдәге зур казанышлары өчен;

42) "Татарстан Республикасының Атказанган энергетигы" – предприятиеләрнең, учреждениеләрнең һәм оешмаларның энергетика өлкәсендә кимендә 10 ел эшләүче югары профессиональ белгечләренә энергетиканы үстерүдәге, яңа типтагы энергетика җиһазларын һәм җайланмаларын булдырудагы, проектлаудагы һәм үзләштерүдәге, энергетика объектларын төзүдә, монтажлауда һәм эксплуатацияләүдә экологик хәлне шактый яхшырта торган прогрессив технологияләрне гамәлгә кертүдәге казанышлары өчен, фәнни тикшеренүләрдә, энергияне сакчыл тотуда, җитештерүне оештыруда, кадрлар әзерләүдә ирешкән уңышлары өчен;

43) "Татарстан Республикасының Атказанган юристы" – дәүләт хакимияте, җирле үзидарә, прокуратура органнарында, судта, адвокатурада, уку йортларында, предприятиеләрдә, учреждениеләрдә һәм оешмаларда үз белгечлекләре буенча кимендә 10 ел эшләүче югары квалификацияле юристларга законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытудагы, гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклаудагы, хокукый дәүләт төзүдәге, хокук фәнен үстерүдәге, закон актларын әзерләүдәге, законнарны пропагандалаудагы, юридик кадрлар әзерләүдәге казанышлары өчен.

15 статья. **Татарстан Республикасының мактаулы исеменә күкрәк тамгасы**

1. "Татарстан Республикасының Халык артисты", "Татарстан Республикасының Халык язучысы", "Татарстан Республикасының Халык шагыйре", "Татарстан Республикасының Халык укытучысы", "Татарстан Республикасының Халык рәссамы" мактаулы исемнәренә лаек булган затларга тиешле күкрәк тамгасы тапшырыла. Башка мактаулы исемнәргә лаек булган затларга бердәй үрнәктәге "Татарстан Республикасының Атказанган хезмәткәре" күкрәк тамгасы тапшырыла.

2. Татарстан Республикасының мактаулы исемнәренә лаек булган затлар мактаулы исемгә күкрәк тамгасын күкрәкнең уң ягында йөртәләр, ә бүләкләнүчеләрнең мактаулы исемнәргә башка күкрәк тамгалары булганда, Россия Федерациясе, СССР күкрәк тамгаларыннан соң, Татарстан АССР, Татарстан ССР күкрәк тамгалары алдыннан урнаштыралар.

4 бүлек. **Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләүгә үтенечнамәләр, тәкъдимнәр**

16 статья. **Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләү турында үтенечнамәләр**

1. Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләү турында үтенечнамәләр оешмалар, иҗтимагый берләшмәләр, Татарстан Республикасы дәүләт органнары, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары коллективлары тарафыннан кузгатыла.

2. Бүләкләүгә тәкъдим итү өчен кандидатуралар һәм аларга характеристикалар төп (даими) эшләү урыны буенча коллектив җыелышында, конференциясендә яисә иҗтимагый берләшмәнең сайланулы органы тарафыннан карала һәм раслана, бүләкләү кәгазендә шул хакта язып куела.

Дәүләт бүләкләвенә тәкъдим ителүче затның төп (даими) эшләү урыны булмаса, күрсәтелгән затны бүләкләү турында үтенечнамә аның җәмәгать эшчәнлеге урынында яисә җирле үзидарәнең вәкаләтле органы тарафыннан кузгатыла.

3. Татарстан Республикасы дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары хезмәткәрләрен Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләү турындагы үтенечнамәләр тиешле органнар тарафыннан алар үзләре билгели торган тәртиптә кузгатыла.

4. Федераль дәүләт органнары хезмәткәрләрен Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләү турындагы үтенечнамәләр тиешле органнар йә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан алар үзләре билгели торган тәртиптә кузгатыла.

5. Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләү турындагы үтенечнамәләр буйсынучанлык тәртибендә югарырак органнар тарафыннан кузгатылырга мөмкин.

17 статья. **Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләү турындагы үтенечнамәләрне карау тәртибе**

Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләү турындагы үтенечнамәләрне карау тәртибе, шулай ук үтенечнамәгә кушып бирелә торган документларның һәм белешмәләрнең исемлеге, әлеге Закон нигезләмәләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан билгеләнә. Шул ук вакытта Татарстан Республикасының төрле дәүләт бүләкләре белән бүләкләү үзенчәлекләре исәпкә алына.

18 статья. **Бүләкләү кәгазе**

1. Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләү турында үтенечнамә кузгатылганда, бүләкләү кәгазе тутырыла. Бүләкләү кәгазенең рәвеше Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан раслана.

2. Бүләкләү кәгазе бүләкләү турындагы үтенечнамәгә кушып бирелә.

19 статья. **Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләүгә тәкъдим итү**

1. Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләүгә тәкъдим итү хокукына, әлеге статьяның 2 – 4 өлешләрендә билгеләнгән очраклардан тыш, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ия.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты хезмәткәрләрен Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләүгә тәкъдимнәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы тарафыннан кертелә.

3. Татарстан Республикасы Президенты Аппараты хезмәткәрләрен, җирле үзидарә органнары җитәкчеләрен Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләүгә тәкъдимнәр Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе тарафыннан кертелә.

4. Суд органнары хезмәткәрләрен Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләүгә тәкъдимнәр Татарстан Республикасы Югары, Арбитраж һәм Конституция судлары рәисләре тарафыннан кертелә.

5. Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләүгә тәкъдимнәр Татарстан Республикасы Президентына кертелә. Тәкъдимнәрдә бүләкләүгә тәкъдим ителгәннәрнең казанышлары, алар ирешкән уңышлар кыскача бәян ителә.

20 статья. **Бүләкләү турындагы тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт бүләкләре комиссиясе тарафыннан карау**

1. Дәүләт бүләкләвенә бәйле мәсьәләләрне алдан карауны Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт бүләкләре комиссиясе гамәлгә ашыра, ул дәүләт бүләкләре белән бүләкләү турындагы материалларны бәяли, бүләкләүгә объектив якын килүне тәэмин итә, бүләкләүнең мөмкин булуы, бүләкләргә хокукларны торгызу, бүләкләрдән мәхрүм итү турында бәяләмә, бүләкләү турында тиешле дәүләт актлары проектларын әзерләүгә бәяләмә бирә, әлеге Законда һәм Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт бүләкләре комиссиясе турындагы нигезләмәдә каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

2. Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт бүләкләре комиссиясе, бүләкләнүченең казанышларын исәпкә алып, тәкъдимдә күрсәтелгән бүләкләү төрен үзгәртергә яисә бүләкләүгә тәкъдим итүне, сәбәбен нигезләп, кире кагарга хокуклы.

21 статья. **Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләү турындагы тәкъдимне карауны туктату**

Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләү турындагы тәкъдимне карау түбәндәге очракларда туктатыла:

1) бүләкләү документларындагы белешмәләрнең дөрес булмавы билгеләнгәндә;

2) Татарстан Республикасы дәүләт бүләге белән бүләкләүгә тәкъдим ителгән зат вафат булганда, әлеге Законның 6 статьясында күрсәтелгән затлардан тыш;

3) бүләкләнүче җинаять кылган өчен закон көченә кергән суд карары нигезендә хөкем ителгәндә.

5 бүлек. **Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләү**

22 статья. **Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләү**

1. Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләү әлеге Законда билгеләнгән тәртиптә һәм Татарстан Республикасы Президентының шушы Закон нигезендә кабул ителә торган норматив хокукый актлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

2. Татарстан Республикасы дәүләт бүләге белән бүләкләү турындагы карар Татарстан Республикасы дәүләт бүләге белән бүләкләү турындагы үтенечнамәне карау нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Президентына кертелгән тәкъдим һәм Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт бүләкләре комиссиясе тәкъдиме нигезендә Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан кабул ителә.

3. Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләү Татарстан Республикасы Президентының бүләкләү турындагы указлары белән башкарыла, алар Татарстан Республикасының рәсми массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарыла.

23 статья. **Кабат бүләкләү**

1. Гражданлык батырлыгы өчен яисә Татарстан Республикасы һәм аның күпмилләтле халкы алдындагы аеруча бөек казанышлар өчен бүләкләү очракларыннан тыш, Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләрен алганнан соң кимендә биш ел узгач, яңа казанышлар өчен дәүләт бүләкләре белән кабат бүләкләнергә мөмкин.

2. "Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен" ордены белән бүләкләнүдән тыш, Татарстан Республикасының бер үк исемдәге дәүләт бүләкләре белән кабат бүләкләү башкарылмый.

3. Һөнәре буенча Россия Федерациясе мактаулы исеме бирелгән зат, әлеге статьяның 1 өлешендә билгеләнгән таләпләрне исәпкә алып, Татарстан Республикасының шундый ук мактаулы исемен бирүгә тәкъдим ителергә мөмкин, һәм бу киресенчә дә булырга мөмкин.

4. Татарстан Республикасы мактаулы исеме бирелгән зат, әлеге статьяның 1 өлешендә билгеләнгән таләпләрне исәпкә алып, Татарстан Республикасының бүтән мактаулы исемен бирүгә тәкъдим ителергә мөмкин.

## 6 бүлек. **Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләрен тапшыру**

### 24 статья. **Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләрен тапшыруга вәкаләтле вазыйфаи затлар**

1. Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләрен тапшыру Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан башкарыла.

2. Татарстан Республикасы Президенты кушуы буенча һәм аның исеменнән Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләрен түбәндәгеләр тапшыра ала:

1) Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасарлары;

2) Татарстан Республикасы Премьер-министры, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасарлары;

3) Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе;

4) министрлар, дәүләт комитетлары рәисләре, республика башкарма хакимиятенең башка органнары җитәкчеләре;

5) муниципаль районнар (шәһәр округлары) башлыклары.

3. Татарстан Республикасы Президенты Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләрен тапшыруны башка затларга да йөкли ала.

### 25 статья. **Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләрен тапшыру**

1. Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләрен тапшыру, бүләкләү турында Татарстан Республикасы Президенты указы басылып чыккан көннән өч айдан да соңга калмыйча, тантаналы шартларда башкарыла. Татарстан Республикасы дәүләт бүләге бүләкләнүчегә шәхсән тапшырыла.

2. Исән чагында Татарстан Республикасы дәүләт бүләге тапшырылмаган бүләкләнүчене вафатыннан соң бүләкләгән яисә ул вафат булган очракта, дәүләт бүләге һәм шуның таныклыгы бүләкләнүченең гаиләсенә, тагып йөрү хокукыннан башка гына, истәлек итеп саклау өчен тапшырыла (бирелә).

3. Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләрен тапшыру турында яисә аларны бүләкләнүченең гаиләсенә тапшыру (бирү) турында беркетмә төзелә, аңа бүләкне тапшыручы зат тарафыннан имза салына һәм тапшыру башкарылган орган мөһере белән беркетелә.

### 26 статья. **Бүләкләү турында документлар һәм Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләренең номеры**

1. Бүләкләнүчеләргә орден, медаль белән бүләкләү турында һәм Татарстан Республикасының мактаулы исемен бирү турында таныклык тапшырыла, аларның формалары (үрнәкләре) Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан раслана.

2. Орденның, медальләрнең һәм аларга таныклыкларның тәртип номеры була.

7 бүлек. **Бүләкләнүчеләрнең һәм аларның якын туганнарының хокуклары һәм бурычлары**

27 статья. **Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләнүчеләргә ихтирам күрсәтү**

1. Дәүләт органнары, җәмәгать берләшмәләре, шулай ук оешмалар җитәкчеләре, гражданнар бүләкләнүчеләргә хөрмәт һәм ихтирам күрсәтергә тиеш.

2. Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләнүчеләр хезмәттә, хезмәт бурычын һәм гражданнарга Россия Федерациясе Конституциясе һәм Татарстан Республикасы Конституциясе белән йөкләнүче башка бурычларны үтәүдә үрнәк булырга тиеш.

28 статья. **Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләренең сакланышын тәэмин итү**

1. Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләренә лаек булган затлар аларның сакланышын тәэмин итәргә тиеш.

2. Бүләкләү турында документ бүләкләнүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме үзгәрүгә яисә бүләкләнгән оешманың атамасы үзгәрүгә бәйле рәвештә алыштырылмый.

29 статья. **Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләренең дубликатлары**

1. Татарстан Республикасы дәүләт бүләген хәрби вәзгыятьтә, табигый бәла-каза нәтиҗәсендә йә дәүләт бүләген югалтуны кисәтү мөмкинлеге булмаган башка гадәттән тыш хәлләрдә югалткан очракта, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт бүләкләре комиссиясе карары белән бүләкләнүчегә дәүләт бүләгенең дубликаты йә аның муляжы бирелергә мөмкин.

2. Орден, медальләр һәм мактаулы исемнәргә күкрәк тамгалары дубликатларын (муляжларын) бирү турындагы үтенечнамәләр, бүләкләнүчеләрнең гаризалары буенча, бүләкләрнең югалу шартлары тикшерелгәннән соң, бүләкләү турында тәкъдимнәр кертергә вәкаләтле органнар яисә вазыйфаи затлар тарафыннан кузгатыла. Үтенечнамә белән бергә Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт бүләкләре комиссиясенә бүләкләнүченең гаризасы, бүләкләү турындагы документлар һәм дәүләт бүләген югалту сәбәбе турындагы белешмә җибәрелә.

3. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән шартларда югалган дәүләт бүләкләренә документлар урынына документларның дубликатлары Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләренең дубликатларын бирү өчен әлеге статьяда билгеләнгән тәртиптә бирелә.

4. Дәүләт бүләген, дәүләт бүләге документын югалткан барлык башка очракларда бүләкләнүчегә Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләнү турында белешмә бирелә.

30 статья. **Бүләкләнүчеләрнең якын туганнарының хокуклары**

Бүләкләнүчеләр вафат булган яисә аларны вафатыннан соң бүләкләгән очракта, Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре варисларда кала. Мирас итеп алу граждан законнарында билгеләнгән тәртиптә башкарыла. Варислар булмаганда дәүләт бүләкләре Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт бүләкләре комиссиясенә кире кайтарылырга тиеш.

31 статья. **Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләрен саклау өчен музейларга тапшыру тәртибе**

1. Вафат булган бүләкләнүченең яисә вафатыннан соң бүләкләнүченең Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре, варислар ризалыгы белән, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт бүләкләре комиссиясе карары буенча һәм музейның мәдәният өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы тарафыннан хупланган үтенечнамәсе булганда, дәүләт яисә муниципаль музейларга тапшырылырга мөмкин.

2. Саклау һәм экспонат итеп файдалану өчен музейларга тапшырылган Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре вафат булган бүләкләнүченең варисларына кире кайтарылмый.

3. Дәүләт бүләкләрен саклау өчен алу турындагы актны тиешле музей Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт бүләкләре комиссиясенә җибәрә.

4. Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре дәүләт бүләкләрен саклау өчен кирәкле шартлар белән тәэмин ителмәгән музейларда саклана алмый.

8 бүлек. **Бүләкләү турындагы указларны юкка чыгару, дәүләт бүләкләреннән мәхрүм итү, Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләренә хокукларны торгызу**

32 статья. **Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләүне юкка чыгару**

1. Татарстан Республикасы Президенты, әгәр Татарстан Республикасы бүләге белән бүләкләүгә тәкъдимнең дөрес түгеллеге яисә нигезләнмәгән булуы ачыкланса, бүләкләү турындагы указны юкка чыгара.

2. Бүләкләүне юкка чыгару турында үзенә карата указ чыгарылган затка тапшырылган Татарстан Республикасы дәүләт бүләге һәм шуның документы Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт бүләкләре комиссиясенә кире кайтарылырга тиеш.

3. Дәүләт бүләге белән бүләкләүгә нигезләнмәгән тәкъдим ясауны рөхсәт иткән вазыйфаи затлар законнар нигезендә җаваплы булалар.

33 статья. **Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләреннән мәхрүм итү**

1. Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләреннән мәхрүм итү, авыр яисә аеруча авыр җинаять кылган өчен бүләкләнүче хөкем ителгән очракта, бары тик судның хөкем карары нигезендә генә Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан башкарылырга мөмкин.

2. Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләреннән мәхрүм итү турында Татарстан Республикасы Президенты указы чыгарыла.

3. Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләреннән мәхрүм ителгән затныкы булган Татарстан Республикасы дәүләт бүләге һәм аңа документлар хокук саклау органнары тарафыннан кире алына һәм Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт бүләкләре комиссиясенә җибәрелә.

4. Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләреннән мәхрүм ителгән граждан Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләреннән мәхрүм итү турында Татарстан Республикасы Президенты указы үз көченә кергән көннән Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләнгән затлар өчен Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән ташламаларга һәм өстенлекләргә хокукын югалта.

34 статья. **Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләренә хокукларны торгызу**

1. Бүләкләнүчене дәүләт бүләгеннән мәхрүм итүгә нигез булган хөкем карары реабилитацияләүче нигезләр буенча юкка чыгарылганда, Татарстан Республикасы Президентының бу хакта чыгарылган указы юкка чыгарылырга тиеш.

2. Татарстан Республикасы Президенты Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләреннән мәхрүм ителгән затның Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләренә хокукларын, әгәр бүләкләнүченең бүләкләреннән мәхрүм итүгә сәбәпче булган гамәле иҗтимагый яктан куркыныч булудан туктаса, бүләкләнүченең бүләкләүгә тәкъдим итү хокукына ия органнар яисә вазыйфаи затлар тарафыннан хупланган үтенечнамәсе буенча торгызылырга мөмкин.

9 бүлек. **Йомгаклау нигезләмәләре**

35 статья. **Башка төр бүләкләрне билгеләү тәртибе**

Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасының башка дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары үз карарлары белән тиешле дәүләт органнарының һәм җирле үзидарә органнарының төрле төрдәге бүләкләрен, шул исәптән Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләренә охшамаган исемнәр, күкрәк тамгалары, медальләр булдыра алалар.

Әлеге статьяда күрсәтелгән органнар тарафыннан билгеләнгән бүләкләр турында Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт бүләкләре комиссиясенә хәбәр ителә.

36 статья. **Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләренә карата законсыз гамәлләр кылган өчен җаваплылык**

1. Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләренә тышкы кыяфәте белән охшаган орден, медальләр, күкрәк тамгалары һәм аларга документларны гамәлгә кую һәм әзерләү, шулай ук моңа хокукы булмаган зат тарафыннан Татарстан Республикасы орденын, медальләрен, Татарстан Республикасы мактаулы исемнәренә күкрәк тамгасын тагып йөрү, шулай ук Татарстан Республикасы мактаулы исемнәрен бирү яисә Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләренә карата башка законсыз гамәлләр кылу тыела. Күрсәтелгән гамәлләр законнар белән билгеләнгән җаваплылыкка китерә.

2. Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләренә законсыз ия булган затлардан, шул исәптән дәүләт бүләкләреннән мәхрүм ителгән затлардан, хокук саклау органнары тарафыннан тартып алынган Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре, шулай ук иясе билгеле булмаган дәүләт бүләкләре Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт бүләкләре комиссиясенә җибәрелә.

37 статья. **Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләренә лаек булган затларга социаль ярдәм һәм бүләкләү чаралары**

1. Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләнгән затларга Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән социаль ярдәм чаралары күрсәтелә.

2. "Ана даны – Материнская слава" медале белән бүләкләнгән аналарга әлеге статьяның 1 өлешендә каралган социаль ярдәм чаралары белән беррәттән Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә һәм күләмнәрдә бер мәртәбә акчалата бүләкләү түләнә.

38 статья. **Әлеге Законны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанслау**

Әлеге Законны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанслау Татарстан Республикасы бюджеты чаралары исәбеннән башкарыла.

39 статья. **Күчеш нигезләмәләре**

1. Әлеге Законда каралмаган Татарстан АССР, Татарстан ССР һәм Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләнгән гражданнарга әлеге Законның 7 һәм 8 бүлекләрендә каралган нигезләмәләр кагыла.

2. Татарстан Республикасы Президентына әлеге Закон үз көченә кергәнче тапшырылган һәм билгеләнгән тәртиптә каралмаган бүләкләү материаллары әлеге Законда билгеләнгән тәртиптә һәм таләпләр нигезендә каралырга тиеш.

3. Әлеге Законда каралмаган Татарстан АССР, Татарстан ССР һәм Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләнгән затларга Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләнгәннәр өчен Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән ташламалар һәм өстенлекләр кагыла.

4. Әлеге Законда каралмаган Татарстан АССР, Татарстан ССР һәм Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләнгән оешмалар өчен дәүләт бүләкләрен саклау һәм тапшыру шартлары әлеге статьяның 5 – 8 өлешләре нигезендә билгеләнә.

5. Бүләкләнгән оешма дәүләт бүләген, саклау өчен кирәкле шартларны үтәгән килеш, бөтен кеше күрерлек итеп, үзе билгеләгән урында урнаштыра.

6. Бүләкләнгән оешма үзгәртеп оештырылган очракта, дәүләт бүләге Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт бүләкләре комиссиясе карары буенча шушы оешманың хокук дәвамчысында сакланырга мөмкин.

7. Бүләкләнгән оешма ябылган очракта, Татарстан Республикасы дәүләт бүләге Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт бүләкләре комиссиясенә кире кайтарыла.

8. Бүләкләнгән оешма ябылгач, аның дәүләт бүләкләре Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт бүләкләре комиссиясе карары буенча саклау һәм экспонат итеп файдалану өчен дәүләт музеена яисә муниципаль музейга тапшырылырга мөмкин.

40 статья. **"Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм турында" 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының $5^1$ статьясына үзгәреш кертү хакында**

"Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм турында" 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының $5^1$ статьясындагы 3 пунктының беренче абзацына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 12 (II өлеш), № 12 (III өлеш); 2005, № 2; 2006, № 2 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 5 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 10 (II өлеш), түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

"3. Әлеге статьяның 1 һәм 2 пунктларында санап үтелмәгән Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләнгән затларга түбәндәге социаль ярдәм чаралары күрсәтелә:".

41 статья. **Татарстан Республикасының аерым закон актларының үз көчләрен югалтуын тану турында**

Әлеге Закон үз көченә кергән көннән түбәндәгеләрнең үз көчләрен югалтуын танырга:

1) "Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында" 2004 елның 24 мартындагы 25-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 3 (IV өлеш);

2) "Татарстан Республикасының аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2005 елның 12 декабрендәге 120-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 12 (I өлеш);

3) "Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында" 2007 елның 28 апрелендәге 17-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 4);

4) "Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында" Татарстан Республикасы Законының 21 һәм 22 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында" 2010 елның 30 июнендәге 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 6 (I өлеш);

5) "Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында" 2010 елның 31 декабрендәге 136-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 12 (II өлеш).

42 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе турында**

1. Әлеге Закон рәсми рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Татарстан Республикасы Президенты һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты үзләренең норматив хокукый актларын әлеге Законга туры китерергә, шулай ук әлеге Законны гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган норматив хокукый актлар кабул итәргә тиеш.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2011 елның 10 октябре
№ 74-ТРЗ